РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Шереметьевского сельского
поселенияНижнекамского
муниципального района

423560, Нижнекамский район,
с. Шереметьевка, ул.Октябрьская площадь, 15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама
муниципаль районы
Ширәмәт авылжирлеге
Башкарма комитеты

423560, Түбән Кама районы,
Ширәмәт авылы, Октябрь мәйданы урамы, 15

тел./факс (8555) 33-02-72, электронный адрес: Sheremetevskoe.Sp@tatar.ru, сайт: www.sheremetevskoe-sp.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 31.01.2019 г. № 10

Ширәмәт авыл җирлегендә җирләү
буенча хезмәтләрнең гаранти-
яләнгән исемлеге нигезендә
күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен
раслау турында

«Россия Федерация сендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыручаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә, «2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы карары белән, карар бирәм:

1. 1-нче кушымта һәм 2-нче кушымта нигезендә, җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлегенә таянып, күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 2019 елның 1 февраленнән Ширәмәт авыл җирлегендә җирләү 5946,47 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны Ширәмәт авыл җирлеге уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулайук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзөстемдә калдырам.

Житәкче В.Г. Емельянов

Ширәмәт авыл җирлеге
башкарма комитетының
2019 елның 31гыйнваренда
10 номерлы карарына
1-нче кушымта

Ширәмәт авыл җирлегендә 2019 елның 1 февраленнән
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтүнең атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен документлар рәсмиләштерү | 46,47 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм илтү | 450 |
| 3. Зиратка үлгән кешенең гәүдәсен (мәетен) илтү | 450 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 5 000 |
| Барлыгы | 5946,47 |

Ширәмәт авыл җирлеге
башкарма комитетының
2019 елның 31гыйнварендa
10 номерлы карарына
2-нче кушымта

Ширәмәт авыл җирлегендә 2019 елның 1 февраленнән
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтүнең атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен документлар рәсмиләштерү | 46,47 |
| 2.  Гәүдәне киендерү | 245 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм илтү | 450 |
| 4. Зиратка үлгән кешенең гәүдәсен (мәетен) илтү | 450 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәмкүмү) | 4755 |
| Барлыгы | 5946,47 |